

Мордовия Республикасы Дәүләт Собраниесе рәисе Владимир Чибиркин «Мордовиягә бизнес тур» тобәкара эшкуарлар съездынын йомгаклау чарасында катнашты. Анда Мәскәv, Санкт-Петербург, Түбән Новгород, Смоленск, Сургут, Пенза, Саратов һәм илнен башка шәһәрләреннән эшмәкәрләр, хакимият органнары вәкилләре, предприятие житәкчеләре катнашты. Оч кон дәвамында рес-публикада сәvдә, тозелеш, жинел сәнәгать, хезмәт кvрсәтv олкәсендәге проектларны гамәлгә ашыручы бизнесменнар тәжрибәсе белән уртаклашу мәйданчыгы эшләде. Съезднын максаты - регионнарнын бизнес-интеграциясе һәм икътисади элемтәләрен ныгыту.  Мордовия башлыгы Артём Здунов исеменнән эшлекле кешеләрне Мордовия Дәvләт Собраниесе рәисе Владимир Чибиркин сәламләде: «Бvген тотрыклы vсеш һәм жаваплы бизнес алып бару принципларын алга этәрv бик моһим. Эшкуарлык жәмәгатьчелеге белән эшләv һәм яшьләрне кече бизнеска жәлеп итv республикабыз икътисадында зур роль уйный. Илнен, һәр тобәкнен динамик vсеше шәхси бизнесны vстермичә момкин тvгел. Бу хакта Россия Президенты берничә тапкыр сойләде». Владимир Чибиркин билгеләп vткәнчә, федераль һәм тобәк дәрәжәсендә норматив база бар, ул бизнеснын барлык юнәлешләрендә дә нәтижәле эшләргә момкинлек бирә. РМ Дәvләт Собраниесе спикеры Съездда катнашучыларга Мордовиядә бизнес жәмәгатьчелеккә ярдәм итv очен билгеләнгән салым ташламалары турында сойләде. Шулай ук vз чыгышында Россиягә каршы кертелгән санкцияләрнен икътисаднын кvп кенә секторларына кагылуын билгеләп vтте. Хәзерге вакытта бизнесменнар очен ин моһиме, дип ассызыклады Владимир Чибиркин, икътисадый чылбырларны торгызганда vз урынынны табу. Очрашуда сvз яна чынбарлык шартларында бизнеска ярдәм итvнен федераль һәм региональ чаралары, эшкуарлыкнын хакимият органнары белән хезмәттәшлеге, бизнес-жәмәгатьчелекнен тобәк тормышында катнашуы турында барды. РМ Дәvләт Собраниесенен икътисад, сәнәгать һәм эшмәкәрлек комитеты рәисе Ринат Раимов билгеләп vткәнчә, бизнес vсешендә законнар базасы топ роль уйный. «Хәзер Бизнес-мохитнен эчке базарын интеграцияләv һәм vстерv очен ирешергә кирәк. Без чит ил тиндәшләренә тvгел, ә vзебезнен житештерvчеләрнен хезмәтләрен һәм товарларын алга этәрергә тиеш», – диде Ринат Раимов.

«Деловар» (Саратов шәһәре) эшмә-кәрләр клубы житәкчесе Ольга Хаснутдинова съезднын ябылу олешендә кvргән тәэсирләре белән уртаклашты: «Делегациябез составында 30 кеше. Без Мордовия компанияләре, заводлары, предприятиеләре, жәмәгать туклануы vсешенен югары дәрәжәсенә шаккатабыз. Бик кvп файдалы инсайдлар, идеяләр, илһамнар vз бизнесларын vстерv очен бирелде. Файдалы бизнес-элемтәләр жайга салынды».

Йомгаклау очрашуы фикер алышу форматында узды, бизнес-жәмәгатьчелек вәкилләреннән алдагы эш буенча тәкъдимнәр керде. Мордовия Республикасы Госсобрание рәисе Владимир Чибиркин эшлекле кешеләрне кvбрәк активлыкка, хакимият органнары һәм жәмәгатьчелек белән хезмәттәшлеккә чакырды.

**Наилә НАСЫРОВА әзерләде**